
кабатлыйлар. Кем кабатлый алмый, аны уртага кертәләр һәм уен яңадан башлана.

***Бергәләп өйрәник***



***Минем өй, минем бистә, минем республика***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

## Табышмаклар

* Көн-төн йөри,

Урыныннан китә алмый.

 (Сәгать)

* Почмакта бер суык кыш,

Исеме аның... (суыткыч).

* Төймәсенә басу белән

Бәйли зәңгәр яулыгын.

Аш пешерә, чәй кайната —

Күрсәтә уңганлыгын.

 (Газ плитәсе)

*Сөйләп бирә тел белән,

Сүзе китә юл белән,

Юлы агач башында. (Телефон)

* Үзе бер әрҗә,

Бөтен дөньяны

Күрсәтә. (Телевизор)

* Аяксыз, кулсыз

Өй саклый.

 (Йозак)

**Шәһәр төзим**

Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкле урамнарда
Машина чабып торыр.
Шәһәрнең уртасыннан
Зур елга агып торыр.
Йөзеп арган көймәгә
Дулкыннар кагып торыр.
Бу шәһәрдә кошларга
Таш атмаслар малайлар,
Усал малайлар күреп
Абыйлар һәм апалар
Бик-бик тату яшәрләр,
Бер-берсенә һәрвакыт
«Исәнме!» дип дәшәрләр.
Төзүче булыр әти,
Әни булыр тегүче.
Абый белән без икәү —
Машиналар йөртүче.
Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкләр, агачларга
Тамчы сибелеп торыр.
Чәчәкләр биеп торыр,
 Гел «рәхмәт!» диеп торыр.

Рәшит Бәшәр

## *«Тимербай» уены.*

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнәләр. Бер бала уртага чыга. Түгәрәктәге балалар хор белән такмак әйтеп әйләнәләр:

- Тимербайның биш баласы,

Бар да матур, күз карасы;

Агым суда коендылар,

Ап-ак итеп юындылар,

Өс-башларын киенделәр,

Рәхәтенә тиенделәр.

Тезелеп кайтып киттеләр,

Ашамадылар, эчмәделәр,

Бер-берсенә караштылар

 – Менә шулай эшләделәр.

Такмак бетүгә уртадагы бала нинди дә булса берәр хәрәкәт ясый. Түгәрәктәге балалар шунда ук аның кыланышларын